**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Базяково торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2025 елның 1 ноябрендәге 1 номерлы**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына туры китереп 2025 елның 31 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде. Җыенга түбәндәге сорау куелган иде «Сез,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге Базяково торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлек студентларыннан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган,МХО да катнашучы һәм инвалидларыннан тыш,2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә,түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны яктыртуны җайлау;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 103 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар, җыенында катнашучылар саны 83 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Яклыйм» позициясе өчен гражданнар җыенының 83 катнашучысы тавыш бирде;

җыенда 0 катнашучы «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Базяково торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныйрга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныйрга.

2. «Сез,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге Базяково торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлек студентларыннан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган,МХО да катнашучы һәм инвалидларыннан тыш,2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә,түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны яктыртуны җайлау;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.-сораулары буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Войкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr:/ / pravo. tatarstan.ru)бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы Войкино
авыл җирлеге башлыгы ____________Н.П. Шабутдинова
(имза) (имзаның расшифровкасы)